ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 26 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) унөченче абзацта “гамәлгә ашыруга вәкаләтле органыннан (алга таба – хокукларны теркәү органы)” сүзләрен “гамәлгә ашыручы органыннан (алга таба – хокукларны теркәү органы) һәм аның территориаль органнарыннан” сүзләренә алмаштырырга;

2) унтугызынчы абзацта “гражданнарның” сүзен “өлешле төзүдә катнашучыларның” сүзләренә алмаштырырга;

3) егерме өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“мәҗбүри таләпләрне бозуның җинаять җаваплылыгына тартырлык гамәлләр кылу билгеләре булган фактлары ачыклануга бәйле материалларны җинаять эшләре кузгату турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен хокук саклау органнарына җибәрү;”;

4) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасына Федераль законның $23^{3}$ статьясындагы 5 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматны урнаштыру.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 13 ноябрь
№ 82-ТРЗ